Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы
Югары Кондрата авыл җирлеге Советы

КАРАР

2025 елның 27 марты № 62/1

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Югары Кондрата авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы 25, 26 статьялары, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Югары Кондрата авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 27 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Югары Кондрата авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Югары Кондрата авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун елга расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын да кертеп, аның график сурәте белән бергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән, шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (https://chistopol.tatarstan.ru/) урнаштыру юлы белән Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Югары Кондрата авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча чыгарырга:

Югары Кондрата ур., Центральная ур., 35/1 (административ бина);

Югары Кондрата ур., Центральная ур., 39 А йорт (кибет бинасы)

3. Карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Югары Кондрата авыл җирлеге
башлыгы Ф.П. Чалмаев

Чистай муниципаль районы
Югары Кондрата авыл җирлегенең
2025 елның 27 мартындагы
62/1 номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Югары Кондрата авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасы

| № т/б | Сайлау округы исеме | Округ чикләре | Сайлаучылар саны |
|---|---|---|---|
| 1 | 1 нче Горький | М.Горький урамы 1-8 йортлар (барлык йортлар),<br>Центральная урамы 1-23 йортлар (так ягы) | 28 |
| 2 | 2 нче Центральный | Центральная урамы 2-38 йортлар (җөп ягы) | 33 |
| 3 | 3 нче Новиков | Центральная урамы 29-31 йортлар (так ягы),<br>П.Новиков урамы 1,3,5 йортлар (так ягы), 2-26 йортлар (җөп ягы) | 29 |
| 4 | 4 нче Кондрата | Центральная урамы 25 нче йорт,<br>П. Новиков урамы 7-31 йорт (так ягы),<br>Бутлеров урамы 1-4 йортлар | 32 |
| 5 | 5 нче Бутлеров | Бутлеров ур. 6-19 йортлар (барлык йортлар),<br>П.Новиков урамы 28-32 йортлар (җөп ягы),<br>И.Чалмаев урамы 1 йорт | 28 |
| 6 | 6 нчы Восточный | Восточная урамы 2-14 йортлар (барлык йортлар),<br>И. Чалмаев ур. 6,7,8,9,10 йортлар | 27 |
| 7 | 7 нче Чалмаев | И.Чалмаев ур. 11-22 йортлар (барлык йортлар) | 27 |